КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 июнь г.Казань № 331

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Күчемсез милеккә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәдә:

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктның җиденче абзацында «күчемсез милекнең дәүләт кадастры» сүзләрен «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\331.docx